КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 29 май г.Казань № 386

Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чараларын тормышка ашыру турында

Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чараларын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгын Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чараларын тормышка ашыруның төбәк координаторы итеп билгеләргә.

2. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру буенча чаралар комплексын («юл картасын») расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 29 май, 386 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру буенча
чаралар комплексы («юл картасы»)

| Т/с | Татарстан Республикасы йөкләмәләре | Гамәлләр | Сроклары | Җаваплылар |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру | | | | |
| 1. | Төбәк ведомство проект офисы составында авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру өчен җаваплы вазыйфаи затны раслау | ТР МһФМ боерыгын әзерләү* | 2021 елның беренче яртыеллыгы | ТР МһФМ |
| «2. | Авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру өчен муниципаль берәмлекләр буенча субсидия бүленешен раслау | ТР МһФМ боерыгын әзерләү | 2021 елның беренче яртыеллыгы | ТР МһФМ |
| 3. | Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру буенча чаралар исемлеген башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында муниципаль берәм- | Муниципаль берәмлекләр белән субсидия бирү турында килешү | 2021 елның бюджет йөкләмәләрен исәпкә кую датасыннан 30 календарь көннән дә соңга калмыйча | ТР МһФМ |

*Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге – 4 нче биттә.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | лекләр бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар бирү турында килешү төзү | | | |
| «4. | Капиталь ремонт буенча төзелеш-монтаж эшләрен башкаруга сатып алулар процедураларын үткәрү | Сатып алулар процедураларын үткәрү | 2021 елның беренче яртыеллыгы | ТР МһФМ, ТР Төзелеш министрлыгы, ТР БИТИ |
| 4.1. | Проект-смета документациясен әзерләү | Проект-смета документациясен әзерләү | 2021 елның беренче яртыеллыгы | ТР МһФМ, ТР Төзелеш министрлыгы, ТР БИТИ |
| | | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының чараны гамәлгә ашыру турындагы норматив хокукый актларын әзерләү | 2021 елның беренче яртыеллыгы | ТР МһФМ, ТР Төзелеш министрлыгы, ТР БИТИ |
| 4.2. | Эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны игълан итү | Сатып алулар үткәрү турында белдерүләр урнаштыру | 2021 елның 1 июненә кадәр | ТР МһФМ, ТР Төзелеш министрлыгы, ТР БИТИ |
| 4.3. | Спорт залларында ремонт эшләрен башкару. Эшләр башкару актына кул кую | Эшләр барышын тикшерүдә тоту, эшләрне кабул итү актларын, товар йөкнамәләрен әзерләү һ.б. | 2021 елның 31 августына кадәр | ТР МһФМ, ТР Төзелеш министрлыгы, ТР БИТИ |
| «5. | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидия бирү турындагы килешүнең 4.2.1 пункты нигезендә авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру буенча Татарстан Республикасында гамәлгә ашырыла торган чараларны тормышка ашыру мониторингын үткәрү | Чараларны тормышка ашыру мониторингын үткәрү | Ай саен, 2021 елның хисап аеннан соң килә торган айның 1енә кадәр | ТР МһФМ |
| 6. | «Электрон бюджет» ГБМ системасында 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына субсидия бирү турында килешү проектын электрон рәвештә алдан килештерү (имза кую) | Финанс буенча килешүгә имза кую | 2021 елның 15 августына кадәр | ТР МһФМ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 7. | «Мәгариф» илкүләм проекты брендбукын файдаланып, гомуми белем бирү оешмаларының яңартылган матди-техник базасын рәсмиләштерү эшенә мониторинг үткәрү | ТР МһФМ боерыгы белән расланган мониторинг үткәрү өчен форма эшләү | 10.08.2021 | ТР МһФМ |
| | | «Мәгариф» илкүләм проектының ведомство проект офисы тарафыннан билгеләнә торган форма буенча мониторинг үткәрү һәм аның нәтиҗәләре турында боерык | 20.08.2021 | ТР МһФМ |
| 8. | Авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен матди-техник базаны яңарту чарасының нәтиҗәләренә үзгәрешләр кертү өлешендә «Һәр баланың уңышы» төбәк проектын тормышка ашыру турындагы килешүгә өстәмә килешү төзү | Финанс булмаган өстәмә килешү төзү | 2021 елның 15 сентябренә кадәр | ТР МһФМ |
| 9. | 2021 елда «Һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру турында хисап видеороликгын әзерләү | Хисап видеороликгын әзерләү | 2021 елның 25 октябренә кадәр | ТР МһФМ, гомуми белем бирү оешмалары (килешү буенча) |
| 10. | «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына һәм (яки) «Мәгариф» илкүләм проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проекты чараларын тормышка ашырганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен федераль бюджеттан финанслашуның иң чик күләмен исәпкә алып билгеләнә торган күләмдә бюджет ассигнованиеләрен актуальләштерү өлешендә һәм 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына субсидияләр акчасын тормышка ашыру нәтиҗәләрен «Һәр баланың уңышы» төбәк проекты нәтиҗәләренә туры китерү өлешендә 3 елга авыл | ТР МһФМ тарафыннан расланган дәүләт программасыннан өземтәне Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгына тапшыру | 2021 елның 15 ноябренә кадәр | ТР МһФМ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру буенча чаралар исемлегенә үзгәрешләр кертү | | | |
| 11. | «Мәгариф» илкүләм проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проекты чараларын тормышка ашырганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен федераль бюджеттан финанслашуның иң чик күләмен исәпкә алып билгеләнә торган күләмдә бюджет ассигнованиеләрен актуальләштерү өлешендә Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законга үзгәреш кертү | Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы адресына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законнан өземтә бирү | 2021 елның 1 декабренә кадәр | ТР МһФМ |
| 12. | «Электрон бюджет» ГБМ системасының илкүләм проектлары белән идарә итү ярдәмче системасында финанс килешүе төзү | Финанс килешүе төзү | 2021 елның 30 декабренә кадәр | ТР МһФМ |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

ТР МһФМ – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;
ТР Төзелеш министрлыгы – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы;
ТР БИТИ – «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе;
ГБМ системасы – дәүләт берләштерелгән мәгълүмат системасы.